| Республика Татарстан<br>Совет Старомензелябашского<br>сельского поселения<br>Сармановского муниципального<br>района | | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районының<br>Иске Минзәләбаш<br>авыл җирлеге Советы |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 сентябрь 2019 ел № 16

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

12.06.2002 ел, № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» гы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясының 1 пункты, Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрүне тәкъдим итәргә:

«Сез, I,II төркем инвалидлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлардан тыш, Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 200 сум күләмендә узара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тоту белән килешәсезме?:

- Иске Минзәләбаш авылының Октябрьнең 60 еллыгы урамына вак таш җәю (таш ташу);

- Иске Минзәләбаш һәм Кужак авылларында урам яктырткычларын алыштыру;

- Беларусь 320.4 маркалы трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;

- Иске Минзәләбаш һәм Кужак авылларында бәйрәмнәр (Сабантуй, Өлкәннәр көне, 9 Май) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

- Кужак авылы обелискы өчен Бөек Ватан сугышында катнашучылар исемнәре язылган мемориаль такта сатып алу ;

ӘЙЕ ЮК?»

2. Әлеге карар мәгълүмат стендлары һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгы Ә.Р.Мияссарова